# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Азартлы уеннарны оештыруны һәм үткәрүне дәүләт тарафыннан җайга салу өлешендә Татарстан Республикасының аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану һәм Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.1 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 12 мартында
кабул ителде

**1 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) "Татарстан Республикасында уен бизнесына салым ставкалары турында" 2003 елның 23 сентябрендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 һәм` 2 пунктларны (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 9 (II өлеш);

2) "Татарстан Республикасында уен бизнесына салым ставкалары турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 2005 елның 23 ноябрендәге 112-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы дүртенче һәм бишенче абзацларны (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 11);

3) "Татарстан Республикасы территориясендә уен йортларын урнаштыру турында" 2006 елның 5 апрелендәге 25-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 4);

4) Административ хокук бозулар турында 2006 елның 19 декабрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексының 3.9 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш);

5) "Административ хокук бозган өчен салына торган акчалата түләтүне билгеләү алымын үзгәртү өлешендә Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында" 2007 елның 7 ноябрендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының

1 статьясындагы 18 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 11).

**2 статья**

Административ хокук бозулар турында 2006 елның 19 декабрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексының 8.1 статьясындагы икенче өлешендә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7-8 (I өлеш), № 9-10; Ватаным Татарстан, 2009, 29 декабрь; 2010, 16 гыйнвар) "3.9" санын "3.8" санына алмаштырырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 29 марты
№ 9-ТРЗ